Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Яуширмә авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

31.03.2023 ел №28/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Яуширмә авыл җирлеге Советының
2019 елның 24 сентябрендәге
«Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
«Яуширмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый
торган күчемсез мөлкәтне тартып алу турындагы
Нигезләмәне раслау хакында”гы
69/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Чистай шәһәр прокуратурасының 2023 елның 23 мартындагы 02-08-03-2023 номерлы Федераль законнарны бозуны бетерү хакындагы күрсәтмәсенә нигезләнеп, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы 2022 елның 29 декабрендәге 605-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Яуширмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Яуширмә авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Яуширмә авыл җирлеге Советының 2019 елның 24 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Яуширмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне тартып алу турындагы Нигезләмәне раслау хакында”гы 69/2 номерлы Нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. исемендә, преамбуласында, 1 пунктында “тартып алу” сүзеннән соң тиешле килешләрдә “күчемле һәм” сүзләрен белән өстәргә;

1.2. Кушымта исемендә, 1 абзацында, 1.1 пунктында, 2.2 пунктында - "тартып алу" сүзеннән соң тиешле килешләрдә "күчемле һәм" сүзләрен өстәргә;

- 1.2.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

1.2.2. Әлеге Нигезләмәнең гамәли көче түбәндәгеләргә кагылмый:

1) "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба -

"Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" Федераль закон)15 статьясы нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга тапшырылган арендалана торган мөлкәтне тартып алганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр;

2) муниципаль унитар предприятиеләрнең мөлкәт комплексларын хосусыйлаштырганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр;

3) оператив идарә итү хокукында муниципаль учреждениеләргә караган күчемсез һәм күчемле милек;

4) әйләнештә чикләнгән күчемсез һәм күчемле милек;

5) муниципаль күчемсез һәм күчемсез милек, әгәр кече һәм урта эшкуарлык субъекты арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашыру турында гариза бирелгән көнгә (алга таба - гариза) мондый мөлкәтне сату турында белдерү бастырылган, яисә унитар предприятие тарафыннан мондый мөлкәтне читләштерүне күздә тоткан килешү төзелсә;

6) “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" Федераль законның 18 статьясы 4 нче өлеше нигезендә расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән дәүләт мөлкәте, яисә муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелмәгән муниципаль күчемле мөлкәт.

- 3.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.1. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында»гы Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан һәм файдалы казылмалар чыгаруны һәм эшкәртүне (гомумтаралган файдалы казылмалардан тыш) гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан тыш, арендалана торган мөлкәтне муниципаль милектән түләүле читләштергәндә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мондый мөлкәтне базар бәясенә тигез бәядән сатып алуга өстенлекле хокуктан һәм “Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында”гы 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - “Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында”гы Федераль закон) билгеләнгән тәртиптә бәйсез бәяләүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә сатып алуга өстенлекле хокуктан файдалана.

Шул ук вакытта мондый өстенлекле хокук түбәндәге шарт белән гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) ) арендалана торган күчемсез мөлкәт кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелмәгән һәм гариза биргән көнгә ул аларда ике һәм аннан да артыграк вакыт биләүдә һәм файдалануында яисә вакытлыча файдалануда булса, мондый мөлкәтне арендалау шартнамәсе яисә шартнамәләре нигезендә, 159 номерлы Федераль законның 9 статьясы 2.1 өлешендә каралган очрактан тыш.

2) арендалана торган күчемле мөлкәт кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән, күрсәтелгән исемлектә мондый

мөлкәтне 159 номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән мөлкәткә кертү турында белешмәләр юк, һәм гариза биргән көнгә мондый мөлкәт аларның вакытлыча биләвендә һәм файдалануында яисә вакытлыча файдалануында, яисә мондый мөлкәтне арендалау шартнамәсе яисә шартнамәләре нигезендә, ике ел һәм аннан күбрк булса, моңа 159 елның 9 статьясындагы 2 өлешендә каралган очрак керми;

3) 159 номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 4 өлеше нигезендә арендага бирелә торган мөлкәтне сату-алу шартнамәсен төзү көненә, 159 номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 2 өлешендә яисә 2_1 өлешендә каралган очракта гаризаны биргән көнгә, кече яисә урта эшкуарлык субъектлары күчемле һәм күчемсез мөлкәткә аренда түләве буенча неустойкалар (штрафлар, пенялар) буенча бурыч юк;

4) арендага бирелә торган мөлкәтне сату-алу шартнамәсен төзү көненә кече һәм урта эшкуарлык субъекты турында белешмәләр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрыннан төшереп калдырылмаган.

- 4.3 пунктта «түләүле читләшү» сүзләреннән соң «күчемле һәм» сүзләрен өстәргә;

6.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган арендалана торган мөлкәтне түләү күчемсез мөлкәт өчен биш елга һәм күчемле мөлкәт өчен өч ел тигез өлештә айлык яисә квартал саен түләнә торган түләүләр ярдәмендә бер мәртәбә яисә өлешләп башкарыла».

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Яуширмә авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутатлык эшчәнлеге буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яуширмә авыл җирлеге
башлыгы: Л.Р.Гәрәева